**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Кукмара районының аерым территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерү турында**

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Кукмара районы Кукмара шәһәренең Тукай урамы территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Кукмара районының аерым территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2017 елның 7 декабрендәге ПУ-1088 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 09 февраль
№ ПУ-154